КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1260

Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгын булдыру турында

«Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Идел елгасының уникаль ландшафт комплексларын саклап калу, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су янындагы төрләрен саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 29 076 гектар мәйданлы «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгын булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре урнашу урынының график тасвирламасын һәм чикләренең характерлы нокталары координатлары исемлеген.

3. «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләрен һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләрен территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә, җирләргә инвентаризация үткәргәндә исәпкә алырга.

4. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

финанслау башкарылганнан соң, бер ел эчендә «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре турындагы мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына билгеләнгән тәртиптә кертүне тәэмин итәргә.

5. Зеленодольск, Югары Ослан, Лаеш муниципаль районнарының, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитетларына 2023 елның 1 гыйнварына кадәр утраулардагы коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен теркәүгә алуны, шулай ук күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны җыю, чыгару һәм утильләштерүне тәэмин итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин